# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге составына керүче Тугыз торак пунктында (шул исәптән Келәүш урманчылыгы) үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 8 «27» октябрь, 2023 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлегенең Тугыз торак пунктында (шул исәптән Келәүш урманчылыгы) 2023 елның «27» октябрендә узган үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге Тугыз торак пункты (шул исәптән Келәүш урманчылыгы) территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2024 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Тугыз торак пунктында һәйкәл территориясен төзекләндерү (материаллар сатып алу һәм килешү буенча эш өчен түләү);
- Тугыз торак пунктында махсус җиһазлар сатып алу һәм лампочкалар урнаштыру;
- Тугыз торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

- Келәүш урманчылыгында Завод урамына вак таш җәеп ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Келәүш урманчылыгында махсус җиһазлар сатып алу һәм лампочкалар урнаштыру;
- Келәүш урманчылыгында юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 102 кеше кертелгән;
гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 57 кеше, 55,9 % тәшкил итә:

Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 57 граждан тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлегенең Тугыз торак пунктында (шул исәптән Келәүш урманчылыгы) узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлегенең Тугыз торак пунктында ( шул исәптән Келәүш урманчылыгы) түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге Тугыз торак пунктында (шул исәптән Келәүш урманчылыгы) территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2024 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Тугыз торак пунктында һәйкәл территориясен төзекләндерү (материаллар сатып алу һәм килешү буенча эш өчен түләү);
- Тугыз торак пунктында махсус җиһазлар сатып алу һәм лампочкалар урнаштыру;
- Тугыз торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

- Келәүш урманчылыгында Завод урамына вак таш җәеп ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Келәүш урманчылыгында махсус җиһазлар сатып алу һәм лампочкалар урнаштыру;
- Келәүш урманчылыгында юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

3. Әлеге карарны Келәүш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Келәүш авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе Б.В.Иванов